**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**03.06.2021** **№ 495**

**Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау хакында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон, 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законы, Башкарма комитетның 2021 елның 17 маендагы 51 номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган турында» боерыгы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын кушымта нигезендә расларга.

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

2018 елның 30 мартындагы 719 номерлы «Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы

йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Федераль законның 3 статьясының 2 өлеше, 20 һәм 21 статьялары белән билгеләнгән таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламенты»н раслау турында».

2019 елның 12 августындагы 1161 номерлы «Төзүчегә төзүченең һәм проект декларациясенең “Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2004 ел, 30 декабрь, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлеге, 20 һәм 21 статьялары белән билгеләнгән таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта
«Расланды»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 03 июнендәге 495
номерлы карары белән

**Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты**

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент төзүчегә «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә төзүченең һәм проект декларациясенең туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба - дәүләт хезмәте).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар булып торалар:

а) өлешле төзелеш объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган очракта:

төзүчеләр- хуҗалык җәмгыятьләре:

милектә яисә аренда хокукында, субаренда хокукында яисә 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законда, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукында җир кишәрлегенә ия булган һәм өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә әлеге җир кишәрлегендә төзелешкә алынган рөхсәт нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын, җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, төзү (булдыру) өчен җәлеп итүчеләр;

б) өлешле төзелеш объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган очракта:

төзүчеләр- хуҗалык җәмгыятьләре:

милектә яисә аренда хокукында, субаренда хокукында яисә 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль

законда, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукында җир кишәрлегенә ия булган һәм өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә әлеге җир кишәрлегендә төзелешкә алынган рөхсәт нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын, җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, төзү (булдыру) өчен җәлеп итүчеләр;

атамаларында «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре булган.

Мөрәҗәгать итүче булып хуҗалык җәмгыяте җитәкчесе яисә аның вәкаләтле вәкиле булып торырга мөмкин.

1.2.1. Проект декларациясе, 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3.2 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән физик затның күрсәтелгән статья таләпләренә туры килүе турындагы мәгълүматны төзүче торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында үзенең шәхси кабинеты аша, көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып, проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән җибәрә.

1.3. Дәүләт хезмәте Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен башкаручы - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге (алга таба - Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: 422700, Татарстан Республикасы, Биектау т/юл.ст.пос., Кооперативная ур., 5 й.

Бүлекнең урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Биектау т/юл.ст.пос., Кооперативная ур., 5 й., 113 каб.

Эш графигы:

дүшәмбе– җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Көндезге аш: 12.00 дән 13.00 кә кадәр.

Белешмә өчен телефоннар: 8(84365)2-30-68.

Керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтының адресы (алга таба - «Интернет» челтәре): (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) Башкарма комитет биналарында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларында) дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi.tatar.ru);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) Бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (Бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазьдә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша (электрон почта адресы – Raniya.Sibgatullina@tatar.ru).

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – Шәһәр төзелеше кодексы) («РФ Законнар җыентыгы», 03.01.2005, N 1, (1 өлеш), 16 ст.);

- 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба –Торак кодексы) ((«РФ Законнар җыентыгы», 03.01.2005, N 1, (1 өлеш), 14 ст.);

- 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Җир кодексы (алга таба –Җир кодексы) («РФ Законнар җыентыгы», 29.10.2001, №44, 4147 ст.);

- 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында» Федеральный закон (алга таба - N 214-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2005, N 1, 40 ст.);

- 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №314179, ст.);

-2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законы (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

- 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законы (алга таба - 66-ТРЗ номерлы ТР Законы) («Татарстан Республикасы», №259, 28.12.2007);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 25 сентябрендәге 1133 номерлы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы сайты адресын билгеләү турында» карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1133 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 01.10.2018, №40, 6137 ст.);

- 2007 елның 05 мартындагы 145 номерлы «Проект документларына һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм уздыру тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары (алга таба –РФ

Хөкүмәтенең 145 номерлы карары) («РФ Законнар җыентыгы», 12.03.2007, №11, 1336 ст.);

- Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект декларациясе рәвешен раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 996/пр номерлы боерыгы) (хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы www.pravo.gov.ru), 30.12.2016, 0001201612300099 ст.);

- Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 11 декабрендәге 653/пр номерлы «Төзүче һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә формасын раслау турында» боерыгы (алга таба – России Төзелеш министрлыгының 653/пр номерлы боерыгы) (хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 28.12.2018, 0001201812280059 ст.);

- Биектау муниципаль районы Советының 2020 елның 19 октябрендәге 14 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы уставы;

- Биектау муниципаль районы Советы 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУ турында нигезләмә (алга таба –Башкарма комитет турында нигезләмә);

- Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2010 елның 30 декабрендәге 3338 номерлы «Эчке тәртип кагыйдәләрен раслау турында» карары;

- әлеге Регламент.

1.5. Әлеге регламентта кулланыла торган терминнар һәм аларның билгеләмәсе:

- Бүлек – дәүләт хезмәтен башкаручы булып торучы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге;

- вәкаләтле банк - Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм Россия Банкы тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийларга туры килә торган банклар исемлегенә кертелгән банк. Россия банкы ай саен банкларның күрсәтелгән исемлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында урнаштыра;

- мөрәҗәгать итүчеләр - әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән билгеләмәләр нигезендә төзүчеләр (аларның вәкаләтле вәкилләре);

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк) - дәүләт яисә муниципаль учреждение оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торган), 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне, шул исәптән электрон формада оештыруга вәкаләтле оешма;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны - Татарстан Республикасы муниципаль районы яки шәһәр округы шәһәр (авыл) җирлегендә 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

- техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

## 2 бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| **Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр исеме** | **Стандартка таләпләр эчтәлеге** | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү | «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьсының 6 өлеше 1.2 пункты,19 статьясындагы 2.1-1, 2.2 өлеше (алга |

| | | |
|---|---|---|
| | | таба - 214-ФЗ номерлы Федераль закон) |
| 2.2. Турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеру органы исеме | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты.<br><br>Дәүләт хезмәтен турыдан-туры башкаручы - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 11.05.2017 N 1769-V ДС карары |
| 2.3.Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә (алга таба –туры килү бәяләмәсе) (1 нче кушымта) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясының 6 өлешенең 1.2 пунктчасы |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты проект декларациясен алган көннән алып 30 календарь көн.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктату каралмаган.<br>Мөрәҗәгать итүчегә шушы Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта яки мөрәҗәгать итүчегә мондый бәяләмә бирелгән көннән 60 көн эчендә аларга күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектын өлешле төзүдә беренче катнашучы белән шартнамәне дәүләт теркәвенә алуга документлар бирелмәгән булса, проект декларациясе әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә Биектау муниципаль районы башкарма комитетына кабат юллама бирергә тиеш. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2.1 һәм 2.3 өлешләре<br><br>66-ЗРТ номерлы ТР Законының 1 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5.Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Проект декларациясе (Россия Төзелеш министрлыгының 996/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән формада), 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән физик затның күрсәтелгән статья таләпләренә туры килүе турында мәгълүмат, күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектын өлешле төзүдә беренче катнашучы белән килешү төзелгәнче, әлеге статья таләпләренә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында төзүче тарафыннан, көчәйтелгән квалификация электрон имзасын кулланып, проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән, башкарма комитетка җибәрелә. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2 өлеше, 20, 21 статьялары |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына буйсынулы оешмалар карамагында булган мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынырга мөмкин булган документлар:<br>күчемсез милек объектын файдалануга кертүгә рөхсәттән белешмәләр (җирле үзидарә органнары):<br>төзелешкә рөхсәттән белешмәләр (җирле үзидарә органнары);<br>җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы (җирле үзидарә органнары);<br>проект документациясенә һәм инженер эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы бәяләмәсе («Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасы дәүләт экспертизасы һәм бәяләр билгеләү идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе);<br>юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (Россия Федерациясенең Федераль салым хезмәте);<br>мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү буенча бурычы булмау турында мәгълүмат (белешмәләр) (Россия Федерациясенең Федераль салым хезмәте); | 214-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә башка оешмалар | фактта юридик зат тарафыннан узган/агымдагы финанс елына барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләнгән салымнар суммасы турында белешмәләр (Россия Федерациясенең Федераль салым хезмәте);<br>аерым затның үзендә булган күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан өземтә (белешмәләр) (Россия Федерациясенең Федераль салым хезмәте);<br>мөрәҗәгать итүче объектны төзүне (булдыруны) гамәлгә ашыра торган җир кишәрлегенә карата күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (белешмәләр) (Россия Федерациясенең Федераль салым хезмәте);<br>төзүченең бердәм башкарма органы, төзүченең баш бухгалтеры, физик затның функцияләрен башкаручы, ахыр чиктә турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат - төзүчегә (капиталда биш процентган артык катнашуга ия) ия булган затның ябылмаган хөкем ителүе барлыгы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы);<br>төзүченең бердәм башкарма органы, төзүченең баш бухгалтеры, физик затның функцияләрен башкаручы, ахыр чиктә турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат - төзүчегә (капиталда биш процентган артык катнашуга ия) ия булган затның дисквалификацияләү формасында административ җәзасы булу турында белешмәләр (Россия Федерациясенең Федераль салым хезмәте).<br><br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар белән тапшырылуы яисә башкарылуы каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр башкару;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертелүне раслый торган документларны һәм мәгълүматны тапшыру, моңа 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлар керми;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыру, Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.<br>Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләре булган документларны, шул исәптән мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә тапшырырга хокуклы.<br><br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләре булган документларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Докумкентларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.<br>Туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>аларга карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2.2 өлеше<br>66-ЗРТ номерлы ТР |

| | | |
|---|---|---|
| | йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба - 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) гамәлдә булуы туктатылып тормаган Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә төзелүе гамәлгә ашырыла торган объектка карата дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү;<br>Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 өлешләрендә, 3.2 статьясында билгеләнгән таләпләргә төзүченең туры килмәве фактлары ачыклану;<br>Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә төзүче проект декларациясенең туры килмәве фактлары ачыклану.<br>Мөрәҗәгать итүчегә әлеге пунктның икенче абзацында каралган нигезләрнең туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарткан очракта яки мөрәҗәгать итүчегә мондый бәяләмә бирелгән көннән алып алтмыш көн эчендә аларга күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектын өлешле төзүдә катнашучы белән шартнамәне дәүләт теркәвенә алуга документлар бирелмәгән булса, проект декларациясе әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабат Башкарма комитетка җибәрелергә тиеш | Законы |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма күрсәтә торган хезмәт турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратның максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.12. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуын, шул исәптән электрон формада да теркәү срогы | Проект декларациясе торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына https://наш.дом.рф/ кергән вакыттан алып, бер эш көне эчендә | РФ Хөкүмәтенең 25.09.2018 N 1133 карары |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү | 1) дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмати стендлар белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә. | 1995 елның 24 ноябрендәге 181 номерлы «Инвалидларны |

| | | |
|---|---|---|
| турында соратулар тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре куелган һәм һәрбер дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге белән мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларга инвалидлар өчен үтемлелекне тәэмин итүгә таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла<br>2) инвалидлар түбәндәгеләр белән тәэмин ителә:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-колясканы кулланып);<br>-дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә мөстәкыйль йөрү мөмкинлеге, шулай ук биналар урнашкан территория буенча дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарда мөстәкыйль йөрү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренең ныклы тайпылышлары булган инвалидларны озата бару һәм аларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;<br>- инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләр һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-ноктал шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;<br>- эт-озатучыны дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә аны махсус укытуны раслый торган һәм законнар нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бирелүче документ булганда кертү;<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма хезмәткәрләренең инвалидларга дәүләт хезмәтен башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм күрсәтүе.<br>Әлеге пунктның 2 пунктында күрсәтелгән таләпләр бары тик яңа файдалануга тапшырыла торган яисә объектларга һәм чараларга реконструкция ясау, модернизацияләү үткән таләпләр буенча гына белдерелә. | социаль яклау турында» Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, җирле үзидарәнең башкарма күрсәтмә органы органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>1) документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бина җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашкан булуы;<br>2) кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>3) «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат стендларында, мәгълүмат ресурсларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең бинага каршылыксыз керүен тәэмин итү (бинага уңайлы чыгу һәм аларның чикләрендә күчену);<br>5) инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>3) гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар булмау;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булмау;<br>5) инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында дәүләт хезмәтен күрсәтү гамәлгә ашырылмый. | |

| | | |
|---|---|---|
| (яисә) муниципаль хезмәтләрне 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган күпфункцияле үзәкләрдә (комплекслы сорату) берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату юлы белән дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге яки мөмкин түгеллеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат Биектау муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http:// vysokaya-gora.tatarstan.ru) Бүлек башлыгыннан (шул исәптән телефон аша) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән телефон аша) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорату составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.15. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелсә) һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында консультация интернет-кабул итү бүлмәсе аша яисә ТР дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә алынырга мөмкин.<br>Закон белән электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү каралган очракта, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (https://uslugi.tatar.ru/) яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) аша бирелә | 214-ФЗ номерлы Федераль закон,<br><br>2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль закон |

## 3 бүлек. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы.

3.1.1. Төзүченең һәм проект декларациясенең 214 номерлы Федераль законның 3 статьяның 1.1 һәм 2 өлешләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба –туры килү турында бәяләмә) түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;
- туры килү турында бәяләмә әзерләү һәм бирү яисә туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту;
- техник хаталарны (хаталарны, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

3.2.1. Административ процедураны башлау өчен телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итүе нигез була.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация бирә.

Гариза бирүченең телдән мөрәҗәгатенә җавап гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Граждан мөрәҗәгатькә язмача җавап алырга теләгән очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә язма консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.

Язма мөрәҗәгатькә җавап - мөрәҗәгатьне теркәү датасыннан утыз календарь көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителә торган документациянең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы башка мәсьәләләр.

3.3. Туры килү турында бәяләмәне әзерләү һәм бирү (җибәрү) яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту.

3.3.1. Туры килү турында бәяләмәне бирү (җибәрү) яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы аша (https://наш.дом.рф/) җибәрелгән гаризаны карау;

2) Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру (җибәрү), һәм һәркем файдалана алырлык сайтлардан мәгълүмат алу;

3) Туры килү турында бәяләмәне яисә туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тартуны формалаштыру;

4) Туры килү турында бәяләмәне яисә туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тартуны тапшыру (җибәрү).

3.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле проект декларациясен һәм башка документларны (мәгълүматны) теркәү торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында (https://наш.дом.рф/) гамәлгә ашырыла.

3.3.3. Гаризаны карау.

Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны, документларны карый һәм гаризаны Бүлек башлыгына җибәрә.

Процедураның срогы: алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.3.1. Бүлек җитәкчесе гаризаны, документларны карый һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен бүлек белгеченә җибәрелгән каралган гариза һәм документлар.

3.3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру (җибәрү), һәм һәркем файдалана алырлык сайтлардан мәгълүмат алу.

3.3.4.1. Бүлек белгече дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарга, дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарга, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә белешмәләр алу өчен ведомствоара соратулар җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар шушы Регламентның 3.3.3 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән соратулар.

3.3.4.2. Бүлек соратулары буенча хезмәтне күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан автоматлаштырылган режимда түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

соратуны эшкәртү һәм соратыла торган мәгълүматларны эзләү;

соратыла торган белешмәләрне ведомствоара электрон үзара хезмәттәшлек ярдәмендә формалаштыру яисә соратып алына торган белешмәләр булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар законнарда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яисә белешмәләр бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.3.4.3. Бүлек белгече юридик затка - төзүчегә карата һәркем файдалана алырлык сайтлардан электрон рәвештә мәгълүмат ала:

Россия Федераль салым хезмәте egrul.nalog.ru сайтында - юкка чыгару процедурасы булу (булмау) турында;

Россия Федерациясенең арбитраж судлары kad.arbitr.ru сайтында - банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсе турындагы, административ җәза чарасы сыйфатында эшчәнлекне туктатып тору турындагы карарның булуы (булмавы) турында;

old.zakupki.gov.ru сатып алулар өлкәсендә Бердәм мәгълүмат системасы сайтында - алып барылуы «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырылган намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында белешмәләр булу (булмау) турында;

Россиянең монополиягә каршы федераль хезмәте rnp.fas.gov.ru сайтында - алып барылуы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында (подрядчылар, башкаручылар) белешмәләр булу (булмау) турында;

Россия Федерациясенең сату турында мәгълүмат урнаштыру сайтында torgi.gov.ru - җир кишәрлеген сату буенча аукционда, яисә җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрында мәгълүматлар булу (булмау) турында.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: һәркем файдалана алырлык сайтлардан алынган мәгълүмат.

3.3.5. Туры килү турында бәяләмәне яисә туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тартуны формалаштыру.

3.3.5.1. Административ гамәлләрнең башлауга әлеге Регламентның 3.3.4 пунктында каралган административ гамәлләрнең нәтиҗәләре нигез булып тора.

Бүлек белгече:

әлеге Регламентның 3.3.4 пункты нигезендә һәркем файдалана алырлык сайтлардан һәм ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынган документларны (мәгълүматны) карый һәм анализлый;

Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль берәмлеге шәхси кабинетына торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында (https://наш.дом.рф/) җибәрелгән мөрәҗәгать итүченең проект декларациясендәге мәгълүматның 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве фактын билгели;

мөрәҗәгать итүченең түбәндәгеләрдә билгеләнгән таләпләргә туры килү фактын билгели:

1) мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы «а» пунктчасына туры килгән очракта, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2 статьяларында (218-ФЗ номерлы Федераль закон, 175-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча);

2) мөрәҗәгать итүченең шушы Регламентның 1.2 пунктындагы «б» пунктчасына туры килгән очракта, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1, 2 өлешендә;

туры килү турында бәяләмә проекты яки туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат проекты әзерли һәм Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

Туры килү турында бәяләмә бирү турында карар кабул ителгән очракта, Бүлек белгече әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә форма буенча әлеге бәяләмәне әзерли;

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар шушы Регламентның 3.3.4 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамланганнан соң җиде календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.2. Бүлек башлыгы карар проектын карый, килештерә һәм Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Процедура срогы: алдагы процедура тәмамланганнан соң бер календарь көн дәвамында.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына килештерүгә җибәрелгән килештерелгән карар проекты.

3.3.5.3. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары карар проектын карый, килештерә һәм аны эш кәгазьләре идарәсенә җибәрә яки карар проектына карата кисәтүләр әзерли һәм кисәтүләрне бетерү өчен Бүлек белгеченә җибәрә.

Процедуралар срогы: карар проекты Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына кергән вакыттан алып ике календарь көн.

Процедуралар нәтиҗәсе: эш кәгазьләре идарәсенә җибәрелгән килештерелгән карар проекты яисә карар проектына карата Бүлек белгеченә җибәрелгән кисәтүләр.

3.3.5.4. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары тарафыннан карар проектына кисәтүләр җибәрелгән очракта, Бүлек белгече кисәтүләрне төзәтә һәм аны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына алга таба килештерү өчен җибәрә.

Процедураның срогы: Бүлеккә кисәтүләр белән карар проекты кергәннән соң 1 календарь көн.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына килештерүгә җибәрелгән төзәтелгән карар проекты.

3.3.5.5. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары төзәтелгән карар проектын карый, килештерә һәм аны эш кәгазьләрен алып бару белгеченә җибәрә.

Процедураның срогы: Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына төзәтелгән карар проекты кергән вакыттан алып 1 календарь көн.

Процедура нәтиҗәсе: эш кәгазьләрен алып бару белгеченә җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.6. Эш кәгазьләрен алып бару белгече:

1) карар проектының соңгы вариантын тикшерә;

2) Башкарма комитет вазыйфаи затларының карар проектын тарату реестрында кирәкле визаларының барлыгын (юклыгын) тикшерә;

3) карар проектын бастырып чыгара һәм Башкарма комитет җитәкчесенә имза салырга җибәрә.

Процедураның срогы: әлеге Регламентның 3.3.5.5 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 календарь көн.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә имзага юнәлдерелгән карар проекты.

3.3.5.7. Башкарма комитет җитәкчесе карар проектына кул куя, аны теркәү өчен эш кәгазьләре идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: әлеге Регламентның 3.3.5.6 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 календарь көн.

Процедура нәтиҗәсе: эш кәгазьләре идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.3.5.8. Эш кәгазьләрен алып бару белгече түбәндәгеләрне башкара:

1) Башкарма комитет җитәкчесенең чыга торган хатлары реестрында имзаланган проектны теркәү;

2) карарны Бүлеккә җибәрү.

Процедураның срогы: Башкарма комитет җитәкчесе карар проектын имзалаганнан соң 1 календарь көн.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән теркәлгән карар.

3.3.6. Туры килү турында бәяләмәне яки туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны бирү (җибәрү).

3.3.6.1. Бүлек белгече:

1) торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында туры килү турында бәяләмәне яисә туры килү турында бәяләмәне бирүдән баш тарту турында көчәйтелгән квалификацияле имза белән имзаланган электрон документ формасында урнаштыра.

2) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен, рәсмиләштерелгән карарны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Процедураның срогы: әлеге Регламентның 3.3.5.8 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 календарь көн.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен, рәсмиләштерелгән карарны бирү датасы һәм вакыты турында хәбәр итү.

3.3.6.2. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, бәяләмә бирүдән баш тарту турында хатны кулына тапшыра яисә почта аша тапшырылуы турында хәбәрнамә белән заказлы хат рәвешендә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура әлеге Регламентның 3.3.5.8 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң ике календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән карар.

3.4. Техник хаталарны (хаталарны, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү.

3.4.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Биектау муниципаль районы башкарма комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (2 нче кушымта)

мөрәҗәгать итүчегә техник хатасы булган дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия булган, техник хата булу турында дәлилләүче документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яисә почта аша җибәрелә.

3.4.2. Эш кәгазьләрен алып бару Бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә карауга юнәлтелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.4.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны, документларны карый һәм гаризаны Бүлек башлыгына җибәрә.

Процедураның срогы: алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 календарь көн.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4.4. Бүлек башлыгы гаризаны, документларны карый һәм бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән каралган гариза һәм документлар.

3.4.5.Бүлек белгече:

документларны карый;

техник хаталар булмаган очракта, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турындагы карар проектын әзерли, аны Бүлек башлыгына, архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак үсеше идарәсе башлыгына килештерүгә җибәрә, аннары Башкарма комитет җитәкчесенә имза куярга җибәрә. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында Башкарма комитет җитәкчесе имза куйган һәм теркәлгән карарны Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) шәхсән үзе бирә яисә гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта аша (электрон почтаярдәмендә) җибәрә;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документларга төзәтмәләр кертү максатларында туры килү турында бәяләмәне яки туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат проектын әзерли, әлеге Регламентның 3.3.5.7 пунктында каралган гамәлләрне башкара һәм мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) яңадан рәсмиләшерелгән документны шәхсән имза куйдырып тапшыра, техник хатасы булган документның төп нөсхәсен кайтарып ала, яисә гариза күрсәтелгән адресына почта аша (электрон почта аша) Башкарма комитетка техник хата булган документ нөсхәсен тапшырып, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылган яки кызыксыну белдергән заттан хата булу турында гариза кабул иткәннән соң өч көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4 бүлек. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклауны һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларның проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

3) дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала, яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыру максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә дәүләт хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре һәм Башкарма комитет хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләре турындагы нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Башкарма комитет җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карамаган өчен җаваплы.

Бүлек башлыгы шушы Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре, юридик затлар һәм оешмалар тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5 бүлек. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, КФҮ, шулай ук КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләренең – КФҮгә яки КФҮне гамәлгә куючысы булып торган дәүләт хакимияте гавами-хокукый берәмлегенең тиешле органына (җирле үзидарә органына) - судка кадәр тәртиптә шикаять белдерү хокукына ия.

Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуның, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән соратуның теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерацисе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралмаган өстәмә документлар яки мәгълүмат яисә эшчәнлек таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткән очракта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъекты норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге хокукый актларында моның өчен нигез булмаса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы

күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада тапшырыла.

Шикаятьне почта аша, КФҮ аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http:/ vysokaya-gora.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитет, КФҮ мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдә баш тарткан очракта яки җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять биргән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮ һәм аның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче–физик затның җавап бирү өчен фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), гариза бирүченең яшәү урыны турында белешмә яисә гариза бирүче–юридик затның исеме, урнашкан урыны турында белешмә, элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи заты яисә Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи заты яисә Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән гариза бирүченең килешмәвен раслаучы дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятькә аны биргән дәүләт хезмәтен алучы имза сала.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акча алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаган акчалата чараларны кире кайтару;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 п. күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә .

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавабында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, Башкарма комитет, КФҮ тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә башкарырга кирәк булган алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, әлеге Регламентның 5.8 п. күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләр, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә .

5.11. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Судка шикаять итү.

Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮ, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

1 нче кушымта
Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты

Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә [1]

№________ «___« __________20 ___ел

Төзүченең исеме: ____________________________________________

Төзүченең ОГРНы:____________________________________________

Төзүченең ИННы:_____________________________________________

Төзелеш проекты исеме: ______________________________________

_____________________________________________________________

[1] Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2004 ел, 30 нчы декабрь, 214ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 20 һәм 21 статьялары белән билгеләнгән таләпләренә туры килүе турында бәяләмәне (алга таба – бәяләмә) кәгазьдә биргән очракта бәяләмәдә чистартулар яки өстәп язулар, сызылган сүзләр яки төзәтүләр булмаска тиеш. Бәяләмә өлешле төзелеш өлкәсендә контрольне (күзәтчелекне) тормышка ашыруга вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органының рәсми бланкында рәсмиләштерелә, әлеге органның вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм мөһер белән раслана (булган очракта). Бәяләмәне электрон формада биргән очракта, әлеге бәяләмә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып имзалана.

Капиталь төзелеш объектының адресы:[2] ______________________________

______________________________________________

Төзелешкә рөхсәт № ____________ Бирелү вакыты ______________________
бирелде ______________________________________
(Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы
______________________________________________
яисә төзелешкә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы исеме)

Әлеге бәяләмә төзүченең ______________________

______________________________________________

өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе нигезендә өч һәм аннан күбрәк блоктан торган күпфатирлы йорт (-лар) һәм (яисә) блоклы төзелеш йортларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә хокукын, шулай ук төзүченең һәм проект декларациясенең (

«___« ______________ 20___ ел редакциясендә) төзелеш проекты турында

______________________________________________
(төзелеш проекты исеме)

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый.

Төзүче һәм проект декларациясенең күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы мәгълүматлар әлеге бәяләмәгә кушымтада китерелгән.

Бәяләмә бирүгә вәкаләтле вазыйфаи зат ______________________________
(вазыйфаның исеме)

______________________________ ______________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы– булганда)) (имза)

[2] Капиталь төзелеш объектының, әлеге объектка төзелешкә рөхсәт нигезендә адресы күрсәтелә.

Кушымта
Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турындагы бәяләмәгә

| Туры килүгә таләпләр | | Туры килү турында тамга |
|---|---|---|
| 1 | Төзүченең проект документациясе һәм проект документациясенә экспертизаның уңай бәяләмәсе бар | |
| 2 | Төзүчегә карата юридик затны - төзүчене юкка чыгару процедурасы үткәрелми | |
| 3 | Юридик затка - төзүчегә карата, 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль закон нигезендә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турындагы арбитраж судның карары юк, күрсәтелгән Федераль законда каралган очраклардан тыш | |
| 4 | Юридик затка - төзүчегә карата аның эшчәнлеген административ җәза чарасы буларак туктатып тору турында арбитраж суд карары юк | |
| 5 | Юридик зат - төзүчегә карата намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрларында юридик зат – төзүче турында (шул исәптән төзүченең бер кулдагы башкарма орган функцияләрен башкаручы зат турында), предметы капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау өлкәсендә эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән | |

| | | |
|---|---|---|
| | яисә мондый төзелешне, реконструкцияләүне һәм капиталь ремонтны оештырудан яисә юридик заттан торак урыннарын сатып алудан гыйбарәт булган контрактларда яисә шартнамәләрдә каралган үзенең бурычларын үтәү өлешендә белешмәләрнең булмавы | |
| 6 | Дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге җир кишәрлеген сату буенча аукционда, яисә дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге җир кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучыларның реестрында юридик зат - төзүче турында (шул исәптән төзүченең бер кулдагы башкарма орган функцияләрен башкаручы зат турында) белешмәләрнең булмавы | |
| 7 | Төзүченең коллегиаль башкарма органы, төзүченең коллегиаль башкарма органы әгъзасы булган зат, төзүченең бердән-бер шәхси башкарма органы (аның функцияләрен гамәлгә ашыручы физик зат яисә идарәче компания), яисә төзүченең вакытлы бердән-бер башкарма органы, яисә идарәче компаниянең бердән-бер башкарма органы функциясен башкаручы зат, әгәр ул төзүченең бедән-бер башкарма органы функцияләрен башкара икән, ахыр чиктә турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат - төзүчегә (капиталында биш процентган артык катнашуга ия) ия булган физик зат, шулай ук төзүченең баш бухгалтеры «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясында билгеләнгән таләпләргә туры килә | |
| 8 | Проект декларациясен җибәрү датасына төзүче һәм (яки) аның төп җәмгыяте тарафыннан яки әлеге төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыяте тарафыннан, проект декларациясендә күрсәтелгән, дәүләт теркәве өчен тәкъдим ителгән әлеге күчемсез милек объектларының беренче катнашучы белән өч һәм аннан да күбрәк айга өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре, өлешле төзелеш катнашучыларының чараларын җәлеп итеп тормышка ашырыла торган күпфатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектын кулланылышка кертү срогын бозу фактлары ачыкланмады | |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | Төзүче турында проект декларациясендә күрсәтелгән мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә | |
| 10 | Төзелеш проекты турында проект декларациясендә күрсәтелгән мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә | |

---

Графа «туры килә» форматында тутырыла.

Россия Федерациясе Законнары җыентыгы, 2002, N 43, 4190 ст.; 2019, N 27, 3538 ст.

Реестрлар «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнары җыентыгы, 2013, N 14, 1652 ст.; 2019, N 26, 3318 ст.) һәм 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы «Юридик затларның аерым төрләре товарларын, эшләрен, хезмәт күрсәтүләрен сатып алу турында» Федераль закон нигезендә (Россия Федерациясе Законнары җыентыгы, 2011, N 30, ст.4571; 2019, N 18, ст.2194) алып барыла.

Реестрны алып бару Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясындагы 28 һәм 29 пунктлары нигезендә (Россия Федерациясе Законнары җыентыгы, 2001, N 44, 4147 ст.; 2019, N 31, 4442 ст.) тормышка ашырыла.

2019 елның 27 июнендәге 151-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 16 статьясындагы 8 өлеше (алга таба - 151-ФЗ Федераль закон) нигезендә әлеге Федераль законның 1 статьясындагы 8 пунктындагы «г» һәм «д» пунктчалары үз көченә кергән көнгә кадәр бәяләмә бирүдән күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы тарафыннан төзүченең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 1, 2-6 һәм 8 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү фактлары һәм (яисә) проект декларациясенең әлеге Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (151-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) ачыкланган очракта баш тартыла. Башка нигезләр буенча бәяләмә бирүдән баш тарту рөхсәт ителми.

2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 20 статьясы белән билгеләнде.

2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм

Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 21 статьясы белән билгеләнде.

2 нче кушымта

Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына

ФОРМА

Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән
баш тарту

Биектау муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 214-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә түбәндәге объект буенча проект декларациясе каралды:

___________________________________________________________________________

(проект декларациясе нигезендә объектның исеме)

____________________________________________________ (алга таба - проект декларациясе)

төзүченең____________________________________________________________

(төзүченең исеме, аның урнашкан урыны, ИНН, ОГРН)

__________________________________________________________ (алга таба - төзүченең),

Башкарма комитетка 20__ елның «__» ________кергән.

Төзүче һәм (яисә) проект декларациясе <1> 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән түбәндәге таләпләргә туры килмиләр (туры килми) <2>:

___________________________________________________________________________

(төзүченең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве ачыкланган фактлар, һәм (яисә) проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве фактлары күрсәтелә)

214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 2.2 өлеше нигезендә бәян ителгәнгә бәйле рәвештә, Башкарма комитет төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Әлеге баш тарту проект декларациясен Башкарма комитетка төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә алу максатында кабат бирүгә комачауламый.

Башкарма комитет
җитәкчесе Ф.И.А.

---

<1> Кирәкле вариант калдырыла: төзүче һәм проект декларациясе, я төзүче, я проект декларациясе.

<2>бер вариант калдырыла.

3 нче кушымта

Төзүченең һәм проект декларациясенең 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләре, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына

Татарстан Республикасы ________________ муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә

___________________________нән

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм __________________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:_______________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:______________________________________________________
__________________________________________________________________________
__

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:_______;

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: _________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мине вәкилләгән затның ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мине вәкилләгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | __________________ | ( _________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.) |